**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2019 нче елның “15” нче апреленнән № 104

**«Өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы һәм «Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә карар бирәм:

1. Өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр бирү Тәртибен расларга (1нче кушымта).

2. Өч һәм аннан күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр бирү өчен гаризалар карау буенча конкурс комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).

3. Өч һәм аннан күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр бирү өчен гаризалар карау буенча конкурс комиссиясе турындагы Нигезләмәне расларга (3 нче кушымта)

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә

htt://pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырырга (халыкка игълан итергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фәсахов**

2019 елның «15» апрелендәге
чыккан № 104 номерлы
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе карарына
1нче кушымта

**Өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр бирү Тәртибе**

## 1. Субсидияләр алу хокукына ия булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны сайлап алу категорияләре һәм критерийлары

1.1. Шәхси ярдәмче хуҗалык - авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү буенча эшмәкәрлек дип саналмаган эшчәнлеге формасы. Шәхси ярдәмче хуҗалык шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында гражданин яисә гражданин белән бергә яшәүче гаиләсе әгъзалары тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән һәм (яки) сатып алынган җир кишәрлегендә алып барыла.

1.2. Саву аппаратлары алуга субсидияләр (алга таба-субсидияләр) Яңа Чишмә муниципаль районы составына керүче торак пунктларда теркәлгән гражданнарга һәм Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә өч һәм аннан күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бирелә.

1.3. Субсидияләр гариза нигезендә бирелә.

## 2. Субсидия бирунең максатлары, шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидияләр бирүнең максаты-савым сыерларының баш санын саклап калу һәм терлекчелек продукциясен җитештерүне тәэмин итү, гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларында савым сыерларының баш санын арттыруны стимуллаштыру.

2.2. Субсидияләр бирү шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу буенча хуҗалык кенәгәсеннән алынган өземтә нигезендә башкарыла, анын күләме мөрәҗәгать итү датасына савым аппараты бәясенең НДСны исәпкә алмыйча һәм монтажлау һәм транспорт хезмәтләре күрсәтүдән башка, 50 проценты күләмендә, бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка бер елга 3 һәм аннан күбрәк савым сыерлары исәбеннән бер саву аппаратыннан артык булмаска тиеш.

2.3. Субсидияләр алу өчен гражданнар яшәү урыны буенча авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге документлар тапшыралар:

- субсидия бирү һәм йөкләмә алу турында гариза (әлеге Тәртипкә кушымта);

- авыл җирлеге тарафыннан расланган сату-алу (китерү) килешүе күчермәсе, алдагы яки агымдагы елда сатып алынган сыер саву аппараты хакын раслаучы түләү документлары (квитанция, касса чегы яки банк выпискасы һәм түләү поручениесе)

- гариза бирүченең паспорты нөхсәсе;

- банк реквизитлары (гариза бирүченең саклык кенәгәсе нөхсәсе);

- субсидия алу өчен тапшырылган документларны караудa катнашучыларга субсидия һәм аннан файдалану буенча бирелгән шәхси мәгълүматка кагылышлы мәгълүматны эшкәртүгә ризалык (әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта).

Шәхси ярдәмче хуҗалыкта гражданнар тарафыннан алынган йөкләмә вакытыннан алда савым сыерларының баш саны үлем аркасында кимегән яки авыру сәбәпле мәҗбүри суелган очракта, гражданнар авыл җирлекләренең башкарма комитетларына ветеринария белешмәләрен һәм билгеләнгән тәртиптә малларның яраксыз икәнлеге күрсәтелгән актны тапшыралар.

2.4. Авыл җирлекләренең башкарма комитетлары:

а) субсидияләр бирү турындагы гаризаларны кергән көнне үк битләре номерланган, тегелгән, печать белән беркетелгән журналга теркиләр, һәм элеге Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә тапшырылган документларны карыйлар.

Документлар гариза теркәлгән көннән башлап 3 көн өчендә каралырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән тәртиптә документларда булган мәгълүматларның дөреслеген тикшерә;

в) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең мәгълүмат системасы буенча ведомствоара документлар әйләнеше кысаларында мөрәҗәгать итүче - шәхси ярдәмче хуҗалык буенча мәгълүматны сорап ала:

- шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу буенча хуҗалык кенәгәсеннән өземтә;

- саву аппаратының бәясен кайтару турында гариза тапшырган айның 1 числосына милек салымнары буенча бурычларның (җир, милек, транспорт) булмавы турында салым органыннан белешмә;

- агымдагы елда һәм алдагы өч елда үзара салым буенча бурычлар булмавы турында авыл җирлегеннән белешмә;

в) әлеге Тәртипнең шул пунктында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә. субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре төзи.

2.5. Әлеге Тәртипнең 2.3 һәм 2.4 пунктлары нигезендә, авыл җирлеге башкарма комитеты гаризаны карау өчен, субсидияләр бирү өчен җыелма белешмәләр-исәп-хисап документларын 3 эш көне эчендә район конкурс комиссиясенә тапшыра.

2.6. Район конкурс комиссиясе әлеге Тәртипнең 2.3 һәм 2.4 пунктлары нигезендә тапшырылган җыелма белешмәләр-исәп-хисап документларын алганнан соң белешмәләр-исәп журналында регистрацияли һәм 3 эш көне дәвамында тиешле авыл җирлегенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларына субсидия бирү (баш тарту) турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарларны конкурс комиссиясе әгъзаларының 2/3сеннән ким булмаган имзалар белән рәсмиләштерә.

Субсидия түбәндәге очракларда бирелмәскә мөмкин:

- тулы булмаган комплект документлар тапшыру яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

- бюджет йөкләмәләренең лимитлары җитмәү.

Бюджет йөкләмәләренең лимитлары җитәрлек булмаган очракта субсидияләр гариза бирү чираты тәртибендә бирелә (2018 елдан башлап).

Субсидияләр бирүдән баш тарткан очракта, район конкурс комиссиясе бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән сроктан соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек срокта бу хакта шәхси ярдәмче хуҗалыкларга хәбәр итә.

2.7. Имзаланган беркетмәнең бер нөсхәсе конкурс комиссиясе документларында саклана, икенче нөсхәсе акча күчерү өчен гариза әзерләү өчен авыл җирлегенә тапшырыла.

2.8. Район конкурс комиссиясе беркетмәсе нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тиешле авыл җирлегенә субсидияләр бирү турында Боерык чыгара.

2.9. Яңа Чишмә муниципаль районының финанс-бюджет палатасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты кабул иткән карар нигезендә, бюджетта тиешле финанс елына авыл җирлекләренең казначылык шәхси счетларына каралган субсидияләр рәвешендә акча күчерүне гамәлгә ашыра.

2.10. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитеты шәхси счетына бюджет акчалары күчкән көннән соң 5 көн өченедә субсидияне гражданнарның хисап счетына кучерә.

2.11. Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, гариза тапшырган гражданнар гамәлдәге законнар нигезендә Башкарма комитет карарына шикаять бирергә хокуклы.

2.12. Әлеге Тәртипнең көче бюджеттан тыш чыгымнар (фондлар) исәбеннән шәхси ярдәмче хуҗалыкларына савым аппараты сатып алганда тотылган чыгымнарны каплау өчен дә җәелдерелә.

## 3. Бюджет акчаларын максатчан куллануны контрольдә тоту һәм отчетлылык

3.1. Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан бирелгән субсидияләр максатчан булмаган кулланылышка кертелгән һәм (яки) субсидия алу өчен тапшырылган документларда ялган мәгълүматлар булу фактлары ачыкланган очракта, район Башкарма комитетының тиешле таләпләрен алган көннән соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты керемнә ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе законы нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

3.2. Әлеге Тәртип нигезендә, гражданнар тарафыннан субсидия алу өчен тапшырган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алуга гариза тапшырган гражданнарга йөкләнә. Коррупциягә каршы закончалыкның үтәлеше Яңа Чишмә Башкарма комитетына һәм авыл җирлекләре Башкарма комитетларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата гамәлдәге законнарда

каралган җаваплылык чаралары кулланыла.

3.3. Бюджет акчаларын максатчан куллануны контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Контоль - исәп палатасы башкара.

Тәртипкә 1 нче Кушымта

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесенә

__________________________________________

________________________________________________
________________________________________________
________________________________________________
________________________________________________
(Ф.И.О., тору урыны)

Гариза
өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр бирү турында

Мин, ____________________________________________________________________,
(Фамилия, имя, отчество)

Паспорт серия _______________, №___________________, _________________________
________________________________________________________________________________
__________________________________________________________тарафыннан ____________ бирелгән,
Тору адресым:_____________________________________________________
___________________________________________________________________________,
телефон ______________________, ИНН ______________________________,
миңа бирелергә тиешле булган өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен бирелә торган субсидияне түбәндәге реквизитлар буенча күчерүегезне сорыйм:___________________________________________________________________
(банк исеме, корсчеты, БИК ; субсидия алучының ИНН , КПП һәм счет номеры)
___________________________________________________________________________.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы, ___________________________________________________________________________ ____________________________________________ адресы буенча урнашкан шәхси хуҗалыгымда савым сыерларының саны __.__.______елда ___________ (_____________________) баш булуы турында хәбәр итәм.

Субсидия алуда катнашу тәртипләре һәм шартлары белән таныштым һәм риза.

Субсидия бирелгән очракта, субсидия алганнан соң өч ел буена савым сыерлары башын киметмәскә һәм тиешле срокларда отчет тапшырырга, субсидияне максатчыл кулланырга йөкләмә алам.Йөкләмә беркетелгән.

Тәкъдим ителгән документларда яки аларның күчермәләрендә булган барлык мәгълүмат чын булып тора һәм субсидия бирү документларын карауда катнашучы затларның аларны өйрәнүенә каршы түгелмен.

___________________ /_________________________/ «____» ___________20__ел.
**(имза)** **(Ф.И.О.)**

# ЙӨКЛӘМӘ

өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен бирелгән субсидияләрне максатчан куллану турында

Мин, ______________________________________________________________________________,
(Фамилия, имя, отчество)

Паспорт серия _____________, №________________, ________________________
______________________________________________________________________________
_________________________________________________________тарафыннан ___________
бирелгән,
Тору адресым:__________________________________________________
______________________________________________________________________________

**йөкләмә алам:**

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «___»___________20__елда чыккан №____" Өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында"гы карары нигезендә өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен бирелгән субсидияне максатчан,
______________________________________________________________________________
___________________________________________________________ адресы буенча урнашкан үз хуҗалыгымда булган савым сыерлары өчен кулланырга.

2. Шәхси хуҗалыгыма бирелгән субсидиянең максатчан кулланылуын тикшерү өчен район комиссиясе әгъзаларына, район башкарма комитеты вәкилләренә каршылыксыз керү мөмкинлеге бирергә, субсидиянең кулланылышы турында кирәкле мәгълүматны тапшырырга.

3. Субсидия алганнан соң кимендә 3 календарь ел буена субсидия бирү турында гаризамда күрсәтелгән савым сыерларының баш санын киметмәскә, малларны тиешле тәртиптә карап торырга.

4. Йөкләмәнең 1-3 пунктларын үтәмәгән очракта – алынган акчаны субсидиянең максатчан булмаган кулланылуы һәм имзаланган йөкләмәнең шартлары үтәлмәве турында акт төзелгәннән соң 60 көн өчендә Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетына кайтарырга.

Әлеге йөкләмәгә кертелгән теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр язма рәвештә башкарылган һәм як-яклар тарфыннан имзаланган очракта гына гамәлдә санала. Әлеге йөкләмәдә күсәтелмәгән башка шартлар буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге кануннары кулланыла. Әлеге йөкләмәне имзалаганда як- яклар анда аңлашылмаган билгеләмәләр булмавы турында килешәләр.

Мин, ____________________________________, "Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә әлеге йөкләмәне төзегәндә һәм башкарганда бирелгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм. Әлеге ризалык кабул ителгән йөкләмәнең бөтен срогына бирелә (имзаланганнан соң 3 елга).

_________________________/________________________________/
(имза) (Ф.И.О.)

Тәртипкә № 2 Кушымта

## Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, _______________________________________________, серия __________ _________________________________________________________________________тарафыннан __________________елда бирелгән паспорт, "Шәхси мәгълүматлар турында" 27.07.06 елда № 152-ФЗ Федераль законның 9 статьясы таләпләре нигезендә, Федераль казначылыкның таныклаучы үзәгенә автоматлаштырылган, шулай ук фамилиясен, исемен, атасының исемен, җенесен, туган датасын, яшәү урынын, шәхесне раслаучы төп документның сериясен, номерын, датасын һәм аны бирү урынын, эш урынын, электрон почта адресы, элемтә өчен(е) телефонын(), Россия Пенсия фондында шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС), Федераль казначылыкның таныклаучы үзәге Регламентында каралган гамәлләрне тормышка ашыру максатларында, минем фамилияләремне, исемемне, атамны, эш урыны турындагы белешмәләрне, электрон почта адресларын, электрон имзаны тикшерү ачкычы сертификатлары булган шәхси белешмәләрнең ачык чыганакларына СНИЛСны, электрон имзаны тикшерү ачкычы сертификатлары реестрын, шулай ук мәгълүмат системаларында катнашучыларның адрес белешмәләрен кертүгә уземнең ризалыгымны бирәм. Федераль казначылык үзәгенә минем шәхси мәгълүматлар белән барлык гамәлләрне (операцияләрне) шул исәптән җыю, системалаштыру, туплау, саклау, яңарту, үзгәртү, куллану, йогышсызландыру, блоклау, юк итү, бастырып чыгаруны гамәлгә ашыру хокукын бирәм.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык "Шәхси мәгълүматлар турында" 27.07.06 елда № 152-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә яисә "Электрон имза турында"гы 06.04.2011 елда № 63-ФЗ Федераль законның 13, 14, 15 статьялары таләпләре нигезендә Федераль казначылык таныклаучы үзәк эшчәнлеге туктатылган очракта кире алынырга мөмкин. Минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны кире алган очракта Федераль казначылык үзәген раслаучының аларны эшкәртүне әлеге килешү гамәлдә булу вакыты тәмамланганчы туктатмаска хокуклы.

Әлеге килешүнең гамәлдә булу срогы - норматив актлар белән билгеләнгән тиешле мәгълүматны саклау вакыты яисә эшкәрткән вакытта минем электрон имза кулланылган документларны саклау вакыты чыкканчыга кадәр.

Элемтә өчен телефон(нар) ____________________________________________

Шәхси мәгълүматлар иясе булган
субъектның имзасы _________________ ______________________________
Ф.И.О. имза

"__" __________ 20__ ел.

Тәртипкә № 3 Кушымта

«Раслыйм»
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе

_______________________________
(имза) (Ф.И.О.)

«_____»_________________ 20__г.

# Хисап - белешмә
## өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен бирелгән субсидияләр бирү буенча

Яңа Чишмә муниципаль районы ______________________________ авыл җирлеге буенча

ОКТМО ____________________

| № п/п | ШЯХ иясенең ФИО | Тору урыны | ИНН | Паспорт мәгълүматлары | __.__.20__елга савым сыерлары саны. | Бер шәхси хуҗалыкка тиешле субсидия ставкасы, % | Барлыгы субсидияләр, сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Мәгълүматлар дөреслеген раслыйбыз:
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
_____________________ авыл җирлеге башлыгы
_____________________ (ФИО)_________________
_____________________авыл җирлегенең баш хисапчысы

/___________________/ ___________________
(Ф.И.О.) (имза)

2019 елның «15» апрелендәге
чыккан № 104 номерлы
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башкарма комитеты
Җитәкчесе карарына
2нче кушымта

**Өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр бирү турында гаризалар карау буенча конкурс комиссиясе составы**

**Конкурс комиссиясе рәисе:**

| | | |
|---|---|---|
| Исхакова Луиза Камил кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары |

**Конкурс комиссиясе рәисе урынбасарлары:**

| | | |
|---|---|---|
| Попкова Надежда Иван кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Богомолов Леонид Евгений улы | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

**Конкурс комиссиясе сәркатибе:**

| | | |
|---|---|---|
| Иванова Нина Николай кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |

**Конкурс комиссиясе әгъзалары:**

| | | |
|---|---|---|
| Завалишина Людмила Леонид кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Прыткова Валентина Александр кызы | - | Түбән Кама шәһәре дәүләт статистикасы бүлегенең (Яңа Чишмә авылындагы) әйдәп баручы белгеч-эксперты (килешү буенча) |
| Темников Вячеслав Виктор улы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча). |

2019 елның «15» апрелендәге чыккан
№ 104 номерлы
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе карарына
3нче кушымта

**Өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр бирү турында гаризалар карау буенча конкурс комиссиясе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр бирү турында гаризалар карау буенча конкурс комиссиясенең эш тәртибен билгели (алга таба – Конкурс комиссиясе).

2.1. Конкурс комиссиясе үзенең эшчәнлеген Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

3.1. Конкурс комиссиясенең шәхси һәм санлы составы Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә һәм раслана..

## 2. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары һәм вазифалары

2.1. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
а) Яңа Чишмә муниципаль районында өч һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары сатып алу өчен тотылган чыгымнарны өлешчә каплау өчен субсидияләр бирү турында гаризалар карау тәтибен оештыру (алга таба - субсидияләр);
б) тиешле формада гаризалар сайлап алу һәм субсидия бирү турында Карар кабул итү.

## Конкурс комиссиясенең хокуклары һәм бурычлары

3.1. Конкурс комиссиясе үз вазифаларын гамәлгә ашыру өчен:

а) субсидия алуга дәгъва итүчеләрдән конкурс комиссиясе эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга һәм билгеләнгән тәртиптә кабул итәргә;

б) субсидия алуга дәгъва итүчеләрне үз утырышларына чакыртырга һәм тыңларга хокуклы.

Конкурс комиссиясе үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен гражданнарга конкурсның үткәрү датасы һәм урыны турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә тиеш.

## 4. Конкурс комиссиясенең эш тәртибе

4.1. Конкурс комиссиясе утырышлары Яңа Чишмә муниципаль районының авыл җирлекләреннән гаризалар һәм исәп-хисап белешмәләрен кабул иткәндә үткәрелә. Кирәк булган очракта конкурс комиссиясенең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

4.2. Конкурс комиссиясе конкурс комиссиясе рәисеннән, конкурс комиссиясе рәисе урынбасарларыннан, конкурс комиссиясе сәркатибеннән һәм конкурс комиссиясе әгъзаларыннан (алга таба – Конкурс комиссиясе әгъзалары) тора.

4.3. Конкурс комиссиясе рәисе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Конкурс комиссиясе эшчәнлегенең гомуми җитәкчелеген гамәлгә ашыра;

2) Конкурс комиссиясенең чираттан тыш утырышын чакыру турында Карар кабул итә;

3) Конкурс комиссиясе утырышларын үткәрү урынын һәм вакытын билгели;

4) конкурс комиссиясе утырышларында рәислек итә;

5) утырыш беркетмәләрен һәм конкурс комиссиясе карарларын имзалый;

6) конкурс комиссиясе кабул иткән карарларның үтәлешен үз компетенциясе чикләрендә контрольдә тота.

4.4. Конкурс комиссиясе рәисе булмаган очракта, аның бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасарларының берсе башкара.

4.5. Конкурс комиссиясе сәркатибе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Конкурс комиссиясе әгъзаларына конкурс комиссиясе утырышының үткәрү урыны һәм вакыты турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

2) Конкурс комиссиясенә кергән документларны һәм материалларны кабул итә, аларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерә, конкурс комиссиясе утырышында карау өчен аларны әзерли;

3) Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен алып бара;

4) конкурс комиссиясе утырышларының беркетмәләрен һәм конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерә.

4.6. Конкурс комиссиясенең башка әгъзалары түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар:

1) Конкурс комиссиясе утырышында һәм конкурс комиссиясе карарлары проектларын әзерләүдә катнашалар;

2) Конкурс комиссиясе компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;

3) Конкурс комиссиясе рәисе йөкләмәләрен үтиләр;

4) тиешле белешмә-мәгълүмат материаллары белән танышалар.

4.7. Конкурс комиссиясе әгъзалары саны 7 кешедән тора (так сан булырга тиеш).

Конкурс комиссиясе утырышы конкурс комиссиясенең кимендә 2/3 әгъзасы катнашса, хокуклы дип санала.

4.8. Конкурс комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Конкурс комиссиясе әгъзаларының тавышлары тигез булганда конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

4.9. Конкурс сайлап алуында катнашучы һәр кеше өчен тавыш бирү нәтиҗәләре утырыш беркетмәсендә теркәлә һәм конкурс комиссиясе карары белән рәсмиләштерелә.

Конкурс комиссиясе беркетмәсенең карары конкурс комиссиясе әгъзаларының кимендә 2/3 әгъзасы тарафыннан имзалана.

4.10. Конкурс комиссиясе әгъзалары үз вазифаларын җәмәгать башлангычында башкара.